**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЫЧЫТКАНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«20»май 2022 ел** **№ 44**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июлендәге 25 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2008 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Кычытканлы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Нигезләмәнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июлендәге 25 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«4.2. Кычытканлы авыл җирлеге территориясендә агач һәм куаклар кисү Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан комиссия тикшерүе акты нигезендә бирелә торган рөхсәт нигезендә 17 эш көне эчендә башкарыла».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Советының Сәламәтлек саклау, санитар һәм экологик эш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Кычытканлы авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.Р. Сабиров